БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ РАЙОН
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

« 24 » апрель 2018 ел № 134

**2018 елда Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы буенча җәмәгать эшләрен оештыру турында**

«Россия Федерациясендә халыкны эш белән тәэмин итү турында» 1991 елның 19 апрелендәге 1032-1 номерлы Россия Федерациясе Законы, «Җәмәгать эшләрен оештыру турында Нигезләмәне раслау хакында» 1997 елның 14 июлендәге 875 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары һәм «Татарстан Республикасында җәмәгать эшләрен оештыру турында» 2009 елның 24 февралендәге 99 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карар бирә:

1. Балтач муниципаль районы территориясендә җәмәгать эшләрен 45 эш урынына кушымта нигезендә оештырырга.

2. «Балтач районының халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» дәүләт казна учреждениесенә (алга таба - «Балтач районының халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» ДКУ) (З.З. Зәйнуллин) түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

- халыкка, туры килә торган эшне эзләү максатларында «Балтач районының халыкны эш белән тәэмин итү үзәге»ндә теркәлгән гражданнарга, шулай ук эшсезләргә оештырыла торган җәмәгать эшләренең төрләре һәм аларны үткәрү тәртибе, шартлары, режимнары һәм хезмәт өчен түләү турында, шулай ук әлеге эшләрне башкарганда оешмалар тарафыннан бирелә торган ташламалар турында хәбәр итәргә;
- эш бирүчеләр белән Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты белән берлектә җәмәгать эшләрен оештыру буенча уртак эшчәнлек турында шартнамәләр төзергә;
- җәмәгать эшләрендә катнашу өчен гражданнарны оешмаларга җибәрергә.

3. Эш бирүчеләргә түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

- Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты белән берлектә «Балтач районының халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» ДКУ белән җәмәгать эшләрен оештыру буенча уртак эшчәнлек турында шартнамәләр төзергә;

- җәмәгать эшләрендә катнашу өчен «Балтач районының халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» ДКУ тарафыннан җибәрелгән гражданнар белән вакытлы хезмәт шартнамәләре төзергә;

- җәмәгать эшләрен оештыру һәм уздыру буенча уртак эшчәнлек турында шартнамә нигезендә оештырылган эш урыннарында гражданнарның мәшгульлеген тәэмин итәргә.

4. «2017 елда Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы буенча җәмәгать эшләрен оештыру турында» 2017 елның 20 апрелендәге 142 номерлы Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карары үз көчен югалткан дип танырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты икътисад һәм фаразлау бүлеге башлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балтач районы башкарма комитеты
җитәкчесе Р.И. Шакиров

Татарстан Республикасы
Балтач район башкарма комитетының
2018 елның 24 апрелендәге
134 номерлы карарына
кушымта

2018 елда Балтач муниципаль районы территориясендә оештырылучы җәмәгать эшләренең төрләре

Файдалануга тапшырыла торган объектларны төзекләндерү;
тротуарларны һәм йөрү юлларын урнаштыру, төзекләндерү;
күчмә ваклап сату челтәре объектларын урнаштыру өчен билгеләнгән территорияләрне төзекләндерү;
оешма һәм учреждениеләр биналары янындагы территорияне төзекләндерү, яшелләндерү һәм чистарту;
автобус тукталышларын төзекләндерү һәм җыештыру.